# “ЧИШМӘ БАШЫ”

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча 6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе

**Ноябрь, 2024 нче ел** **Чыгарылыш №1**


## Нинди яңалыклар бар?

II чирекне уңышлы гына башлап җибәрдек.

Кадерле укытучылар, укучылар һәм әти-әниләр!

Сезне икенче чирек башлану белән котлыйбыз!

Каникуллар бик әйбәт үтте. Укучылар яхшы итеп ял иттеләр, яңа үрләр яуларга, тырышып укырга көч тупладылар. Барлык укучыларга да яңа чиректә бөтен көч һәм мөмкинлекләрен укуга багышлап, аны иң яхшы нәтиҗәләр белән тәмамлауларын телибез.

Барыгызга да яхшы кәеф һәм иҗади уңышлар!

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасы (ВСОШ) — Россия мәктәп укучылары өчен төрле фәннәр буенча ел саен үткәрелә торган ярыш. Ул мәктәп программасына кергән бик күп фәннәрне үз эченә ала: математика, физика, химия һәм башкалар. Олимпиада берничә этапта уза: мәктәп, муниципаль, региональ һәм йомгаклау. Олимпиадада катнашу укучыларга югары уку йортларына кергәндә өстәмә мөмкинлекләр бирә.

Әниләр көне — әниләргә хөрмәт күрсәтү һәм аларның җәмгыятькә кирәкле шәхесләр тәрбияләүдә тиңдәшсез хезмәтләрен олылау өчен билгеләп үтелә торган көн. Бу көн төрле илләрдә төрле даталарда үткәрелә. Россиядә Әниләр көне ноябрьнең соңгы якшәмбесендә билгеләп үтелә. Әниләр көне уңаеннан, гадәттә, балалар әниләренә бүләкләр әзерлиләр, аларга рәхмәт сүзләре әйтәләр һәм гаиләләр бергә җыелып бәйрәм итәләр.




***Мәктәп укытучылары, төрле акцияләрдә катнашып, җәмгыятькә файда китерергә һәм укучыларга үрнәк булырга тырышалар.***

Мәктәп укытучылары "Зур этнографик диктант” акциясендә катнаштылар. "Зур этнографик диктант" – ул Россиядә яшәүче халыкларның мәдәнияты белән таныштыручы, шулай ук этномәдәни грамоталылыкның гомуми дәрәҗәсен бәяләргә мөмкинлек бирүче мәгърифәтчелек проекты.



8 нче ноябрь көнне мәктәп коллективы дөньякүләм «Татарча диктант» акциясенә кушылды. Акциянең төп максаты – татар теленә һәм мәдәниятына игътибар җәлеп итү, дөнья буенча таралып яшәгән татарларны берләштерү, тел белемен тикшерергә мөмкинлек бирү, әдәби татар телен кулланучыларның даирәсен арттыру һәм татар теленә карата мәхәббәт уяту.

Быел «Татарча диктант» акциясе тугызынчы тапкыр оештырыла. Акция - бүгенге көндә Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе һәм чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезне берләштерә торган проектларның берсе.



# *Бердәмлектә-көч!*



2024 нче елның 22 нче ноябрендә Г.Курсави исемендәге лицейда Арча районы мәктәпләре укучылары арасында "Татар кызы, татар егете - 2024" бәйгесе үтте. 8 нче Б сыйныфы укучысы Шәймуллин Данияр Динар улы, искиткеч матур чыгыш ясап, дәрәҗәле 1 нче урынга һәм мәртәбәле "Татар егете - 2024" исеменә лаек булды. Диплом, стена сәгате һәм Р.Зәйдулланың "Татар таҗы" китабы белән бүләкләнде. Чын күңелдән котлыйбыз!

Җитәкчеләре: мәктәбебезнең татар теле укытучылары.

Арча районында «Иң яхшы шашкачы-2024» исеменә шашка буенча ярышларның 4 нче йомгаклау этабы узды! Ярышларда районыбызның 16 мәктәбеннән 115 шашкачы катнашты. Кубок ияләрен котлыйбыз! Иң яхшы шашкачы булып 7 нче В сыйныфы укучысы Вәлиуллин Адель танылды!

Шәхси нәтиҗәләр:

3“Б”сыйныфы укучысы Хәбибуллина Әдилә — 1 нче урын;

3“Г” сыйныфы укучысы Габдулнуров Фидан — 1 нче урын;

6“Б” сыйныфы укучысы Гыйниятова Айзилә — 1 нче урын;

8“В” сыйныфы укучысы Вәлиуллина Әделина — 2 нче урын;

8“Г” сыйныфы укучысы Мәҗитова Рамилә — 2 нче урын.

Шулай ук иң яхшы мәктәп булып, Арча 6 нчы мәктәбе танылды! Котлыйбыз!



Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары командалары арасында уздырылган "КЭС-БАСКЕТ" мәктәп баскетбол лигасы чемпионатында безнең мәктәпнең кызлар командасы II урын алды.

Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары командалары арасында уздырылган "КЭС-БАСКЕТ" мәктәп баскетбол лигасы чемпионатында безнең мәктәпнең малайлар командасы III урын алды.

Тренер: Нәбиуллин Р.Р.

Афәрин! Котлыйбыз!





**Чиста җиңү акциясе** — җәмгыятькә ярдәм итү максатында оештырылган чара.

Мондый акцияләр вакытында кешеләр үзләренең вакытларын, көчләрен җәмгыятькә файда китерүгә багышлыйлар.



# *Олимпиадалар хәрәкәтенең муниципаль этабы башланып китте. Безнең уңышларыбыз:*

**ОБЗР буенча олимпиада җиңүчеләре һәм призёрлары:**
5“А”сыйныфы укучысы
Ибраһимов Айзат-призёр;
8“В”сыйныфы укучысы
Сәлахетдинов Булат-призёр;
8“В”сыйныфы укучысы
Медведкова Анна-призёр;
8“Б”сыйныфы укучысы
Габделнурова Әдилә-призёр;
Укытучылары:Сәйфетдинов Р.Ф.
11“А”сыйныфы укучысы
Мифтахова Азалия-призёр;
Укытучысы:Шакиров И.И.

**Сайлау хокукы буенча олимпиаданың төбәк этабында**
11“А” сыйныфы укучысы
Нурмиева Алия призёр булды.
Укытучысы: Сергиев Д.Ю.

**Инглиз теленнән олимпиада җиңүчеләре һәм призёрлары:**
4“А”сыйныфы укучысы Вафин Бәхтияр-призёр.
Укытучысы:Хәбибуллина А.Р.
4“В”сыйныфы укучысы
Заһидуллин Ильяс-призёр.
Укытучысы:Кәбирова Л.И.
5 “А” сыйныфы укучысы
Локманова Әминә – җиңүче.
Укытучысы: Хәйруллина М.Н.
6 “Б” сыйныфы укучысы
Гыйльфанова Эвелина – җиңүче.
Укытучысы: Җиһангирова Л.И.
8 “В” сыйныфы укучысы
Хәсәнова Әлфинә – призер.
Укытучысы: Хәбибулина А.Р.
8 “В” сыйныфы укучысы
Әгъзәмова Алия –призер.
Укытучысы : Хәбибулина А.Р.
8 “А” сыйныфы укучысы
Гатауллина Әдилә- призер.
Укытучысы: Гыйззәтова Э.Р.

**Рус әдәбияты буенча олимпиада җиңүчеләре һәм призёрлары:**
7 “А” сыйныфы укучысы Гарифуллина Рәфинә - призёр;
7 “А” сыйныфы укучысы Садыйкова Инзилә - призёр;
7 “А” сыйныфы укучысы Сабирҗанова Аделина - призёр.
Укытучылары: Заһидуллина Г. Р.
8“В” сыйныфы укучысы Вәлиуллина Аделина - җиңүче;
8“В” сыйныфы укучысы Медведкова Анна - призёр;
8“В” сыйныфы укучысы Мусина Зилә - призёр;
8 “В” сыйныфы укучысы Фәйзуллина Әминә - призёр.
Укытулары: Заһидуллина Г. Р.
9“А” сыйныфы укучысы Гайфетдинова Алисә - призёр.
Укытучысы: Заһидуллина Г. Р.
9“Г” сыйныфы укучысы Алдосева Кристина - призёр.
Укытучысы: Шәрәфиева Г. З.
10“А” сыйныфы укучысы Әлтапова Зәринә - призёр.
Укытучысы: Гаптелбәрова Д. М.

**Сәнгать фәне буенча олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары:**
10 “А” сыйныфы укычусы
Әлтапова Зәринә – җиңүче;
8 “В” сыйныфы укучысы
Медведкова Анна - призер.
Укытучылары: Галәвиева А.Р.

**Физика олимпиадасы призерлары:**
7 “В” сыйныфы укучысы
Галимҗанов Абдулла.
Укытучысы: Фәттахова А.Р.
8 “В” сыйныфы укучысы
Медведкова Анна.
Укытучысы: Закирова Ф.Ф.
9 “А” сыйныфы укучысы
Котдусов Әмир.
10 “А” сыйныфы укучысы
Абдуллин Әмир.
Укытучылары: Хәмидуллина Ч.Д.

**Экология буенча олимпиада призерлары:**
9“Г” сыйныфы укучысы
Закирова Диләрә.
Укытучысы: Мөхетдинова Л.Н.
10“А” сыйныфы укучысы
Абдуллина Ләйсән.
Укытучысы: Сәгыйтова А.Р.

**Биология фәне буенча олимпиада призерлары:**
7 “А” сыйныфы укучысы
Сабирҗанова Аделина;
7 “А” сыйныфы укучысы
Шәймарданов Әмир;
11“А” сыйныфы укучысы
Мөхәммәтҗанов Расих.
Укытучылары: Мөхетдинова Л.Н.

**География фәне буенча олимпиада җиңүчесе:**
11 “А” сыйныфы укучысы
Мәҗитова Илсөя.
Укытучысы: Сергиев Д.Ю.

**Физик культура буенча олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары:**
8“А” сыйныфы укычусы
Нәбиуллина Зилә-җиңүче
8“А” сыйныфы укычусы
Абдуллин Данияр-җиңүче
8“А” сыйныфы укычусы
Фатыйхова Камилә-җиңүче
9“А” сыйныфы укычусы
Сабиров Аяз-җиңүче;
Призерлар:
6 “А” сыйныфы укычусы Нәбиуллина Алия;
5“Б” сыйныфы укычусы Шәрәфиева Рәфинә;
6“Б” сыйныфы укычусы Сабирова Илсөяр;
6“Б” сыйныфы укычусы Таирова Әдилә
Призерлар:
7“В” сыйныфы укычусы Гаптелбәров Ранель;
6“В” сыйныфы укычусы Сәгыйтов Кәрим;
6“В” сыйныфы укычусы Нигъмәтҗанов Раяз;
6“А” сыйныфы укычусы Ахунов Сәмир;
8“Б” сыйныфы укычусы Загафаров Зөлфәт
9“Б” сыйныфы укычусы
Хәбибуллин Ранил-призер;
9“Б” сыйныфы укычусы
Гарифҗанова Камилә призер.
Укытучысы: Нәбиуллин Р.Р.

## Психолог киңәшләре!

Мәктәпкә уңай караш үстерү буенча ата-аналарга тәкъдимнәр.

1)Мәктәп турында начар сөйләшмәгез, балалар алдында укытучыларны тәнкыйтьләмәгез.

2)Укытучыны шәхси караш булмауда гаепләргә ашыкмагыз, үз тәртибегез турында уйланыгыз.

3)Бала сезнең аның биремнәре, мәктәптән алып кайткан китаплары белән кызыксынуыгызны күрсен.

4)Класс һәм мәктәп тормышында катнашыгыз. Аның мәктәбе сезнең тормышыгызның бер өлеше булып китсә, бала күңеленә хуш килә.

5)Баланы үз фикерләрен язма рәвештә әйтергә өйрәтегез: аның белән язмалар алмашыгыз, бергә хатлар языгыз.

6)Балаларны уен чаралары белән тәрбияләгез.

7)Балагызны вакытында йокларга яткырыгыз. Дәрескә йокысы туймыйча килгән бала - моңсу күренеш.

## Кроссворд

***Горизонталь буенча:***

1. … бала кебек беркатлы кеше ул

3. Чын …. – ул сынала еллар белән, маңгайдагы тирән-тирән сырлар белән.

7. Кешеләр арасындагы бәйләнеш, аларның бер-берсенә булган хисләре фикерләре һәм гамәлләре.

5. Олыларга … кыл, кечеләргә шәфкать кыл.

10. … – гомер чишмәсе.

***Вертикаль буенча:***


2. Беренче …. – гаилә учагы

4. ……… – җепләре

6.… эше – иң изге эш,
… кулы – иң йомшагы,
… йөзе – иң-иң яктысы!

8. Ул зирәк тә, шаян да, акыллы да, әйбәт тә!
Иң – иң батыр кеше ул, минем … әлбәттә!

9. Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул, барыбыздан олы ул.




### Хикәя
### “Минем гаиләм”

Кечкенә чактан үк мин әкиятләргә чын күңелемнән ышана идем. Шуңа күрә дә иң сихри, әкияти Яңа ел бәйрәмен мин аеруча бер ышаныч белән көтеп алам.

Беренче кар ятуга, без чыршыны бизәп тә куябыз: әти утларын көйли, әни иң матур уенчыкларны барлый, ә без сеңелләрем белән аларны чыршыга эләбез. Шул ук кичне кыш бабайга үзебезнең кечкенә генә хыялыбыз турында хат язабыз.

Гадәт буенча Яңа елны без зур гаиләбез белән бергә каршы алабыз. Яңа ел төненә әзерлек алдан ук башлана: гаиләбез белән бергә пилмән бөгәбез, салатлар ясыйбыз. Әби белән бабай үз әбиләре заманыннан сакланып калган рецепт буенча пешерелгән зур бәйрәм бәлешен, кучтәнәч итеп, чигелгән тастымалга төреп алып киләләр.

Бәйрәм сәгатьләре якынлашкан саен,йортыбызга күп кунаклар җыела. Алар белән бергәләп шәһәребезнең иң биек тавына чана шуарга барабыз. Балалар гына түгел,өлкәннәр дә рәхәтләнеп чана шуа. Ап-ак булып, карга батып, без өйгә кайтып керешкә, кыш бабай килеп олысын да, кечесен җырлата, биетә, бүләкләрен өләшә.

Күңелле итеп, барлык туганнарыбызны җыеп, Яңа елны шулай каршы алабыз. Ел да шул ук уеннар, гореф-гадәтләр белән Яңа елны каршы алабыз.

Гаиләбездә башка бәйрәмнәрне дә бергә-бергә бик матур итеп уздырабыз.

Габдулнурова Әдилә, 8 “Б” сыйныф укучысы



Мәктәп сайтына кереп, сез мәктәп тормышы турында мәгълүматлар белән тулырак итеп танышып чыга аласыз: